РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН

**ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ НУРЛАТСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА**

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ

**НУРЛАТ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ**

---

ПОСТАНОВЛЕНИЕ КАРАР

25.01.2021 № 39

Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы муниципаль берәмлеге территориясе чикләрендә территориаль иҗтимагый үзидарәләргә ярдәм итүгә Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы бюджетыннан субсидияләр бирү тәртибенә өстәмәләр кертү турында

Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 18.09.2020 ел, №1492 (30.12.2020 ел ред.) «Субсидияләр, шул исәптән субсидияләр рәвешендә, юридик затларга, шәхси эшмәкәрләргә, шулай ук товар, эшләр, хезмәт күрсәтүләр җитештерүче физик затларга грантлар бирүне җайга салучы норматив хокукый актларга, муниципаль хокукый актларга карата гомуми таләпләр һәм Россия Федерациясе Хөкүмәтенең кайбер актларының һәм Россия Федерациясе Хөкүмәтенең кайбер актларының үз көчләрен югалтуын тану турында» карары нигезендә, Татарстан Республикасы Финанс министрлыгы, Татарстан Республикасы буенча Федераль салым хезмәте идарәсе, Татарстан Республикасы буенча Федераль казначылык идарәсенең 2020 елда Татарстан Республикасы берләштерелгән бюджетын үтәү йомгаклары һәм 2021 елга республика финанс, казначылык һәм салым органнарының бурычлары буенча 2021 елның 4 гыйнварындагы ПР-3 номерлы уртак коллегиясе беркетмәсен үтәү йөзеннән, Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Башкарма комитеты

КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Башкарма комитетының 17.07.2014 ел, №756 карары белән расланган Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы муниципаль берәмлеге территориясе чикләрендә территориаль иҗтимагый үзидарәләргә ярдәм итү өчен Нурлат муниципаль районы бюджетыннан субсидияләр бирү тәртибенә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

5пунктта а), б) өлешләрен түбәндәге абзац белән тулылындырырга:

"салымнар һәм җыемнар турында Россия Федерациясе законнары нигезендә түләнергә тиешле салымнар, җыемнар, иминият кертемнәре, пенялар, штрафлар, процентлар түләү буенча үтәлмәгән бурыч булмау турында белешмә."

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районының рәсми сайтында бастырып чыгарырга.

3. Әлеге карарны Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районының рәсми сайтында бастырып чыгарырга.

Җитәкче Р.Р.Хәмзин